**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА БИКУЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИККОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Биккол ав. **КАРАР**

«22» сентябрь 2023 г. №2

Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегендәге Биккол авылында үзара салым кертү һәм уздыру мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. ТР, Нурлат районы, Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15а йорт адресы буенча Биккол авыл мәдәният йортында Тукай, М. Җәлил, Вахитов урамнарында яшәүче гражданнар өчен Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны 2023 елның 06 октябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. ТР, Нурлат районы Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15а йорт адресы буенча Биккол авыл мәдәният йортында Нурлат районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында Үзәк, Мәктәп урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын уздыруны 2023 елның 07 октябрендә 19 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. ТР, Нурлат районы Биккол авылы, Мәктәп урамы, 15а йорт адресы буенча Биккол авыл мәдәният йортында Нурлат районы Биккол авыл җирлегенең Биккол авылында Заречная, Ленина, Полевая урамнарында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын уздыруны 2023 елның 10 октябрендә 9 сәгать 00 минутка билгеләргә

4. Биккол авылында яшәүчеләрнең исемлеген сайлау тәртибе территориаль билге буенча башкарыла.

5. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Биккол авылында яшәүче гражданнар өчен тәэмин ителә.

6. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2024 елда үзара салым кертүгә Нурлат муниципаль районының Биккол авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә акча кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- янгын сүндерү җиһазларын сатып алу;

- Биккол авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу;

- су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;

- Биккол торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны кыш көне карап тоту.»

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге башлыгы Р.Х. Әхмәтшина